**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең**
**Андреевка торак пунктында гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында**

**17 октябрь 2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Андреевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Андреевка торак пунктында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруның махсус техникасын яллау;
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Андреевка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);
- **киртәләрне ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, чүп савытлары кую, агач кисү, корысарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү, Андреевка торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 48 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 27 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленгән:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 27 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Андреевка авылында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча «2026 елда Шешминка авыл җирлегенең Андреевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Андреевка торак пунктында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруның махсус техникасын яллау;

- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Андреевка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);

- **киртәләрне ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, чүп савытлары кую, агач кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү, Андреевка торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) **кабул ителгән дип таныырга.**

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге башлыгы А.В.Сидоров